КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1361

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм Татарстан Республикасы коткаручысы статусын алучы гражданнарны аттестацияләү буенча комиссия төзү турында» 2014 ел, 26 апрель, 274 нче карары белән расланган Һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм Татарстан Республикасы коткаручысы статусын ала торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм Татарстан Республикасы коткаручысы статусын алучы гражданнарны аттестацияләү буенча комиссия төзү турында» 2014 ел, 26 апрель, 274 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 11 июнь, 462 нче; 2020 ел, 14 август, 686 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм Татарстан Республикасы коткаручысы статусын ала торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Д.Р.Динниуловны, Р.М.Карповны чыгарырга;

комиссия составына Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә караган Магистраль торба үткәргеч транспорт объектларына, газ бүлү һәм газ куллану объектларына күзәтчелек итү буенча төбәкара бүлек башлыгы Никита Андреевич Князьковны (килешү буенча) кертергә;

Таһир Вәгыйзь улы Кәримуллин вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе»;

Нурислам Нуриман улы Хәбипов вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк фәнни-методик ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан филиалы директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин